ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

НОЯБРЬ, 2017нче ел

№3 (34)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**Ноябрьдә**

**иң кадерле кешеләребезне котларга онытмыйк!**

- ✓ **28**– Әниләр көне

## Бала хокуклар дөньясында

11 ноябрь көнне мәктәбебездә "Бала хокуклар дөньясында" дип исемләнгән информацион иртә үткәрелде. Мәктәпкүләм бу чараны тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, 8 нче сыйныф җитәкчесе Фахриева Г.Я. үткәрде. Чара барышында презентация аша балаларның хокуклары аңлатылды. Укучылар Бала хокуклары турында Конвенциянең эчтәлеге белән таныштылар.Республикабызда балаларның хокукларын яклаучы оешмалар эшчәнлеге, бала хокукларын яклаучы белгеч Удачина Гүзәл Любисовна белән контактка керә алу мөмкинлекләре яктыртылды. Уен формасында дәвам иткән чара балаларга истә калырлык һәм файдалы булды.

**Гафурова Алия**

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Юл кагыйдәләрен беләбез, әмма үтәмибез | 2 |
| Якыннан танышыйк! | 3 |
| Гриптан саклан! | 4 |
| Иң көчләр билгеле | 4 |
| Бүләккә—чәчәк! | 4 |
| Иң кадерлем—әнием! | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |


## Халык- без ул!




4 ноябрь көнне Россия халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтә. Бу бәйрәм - чагыштырмача яшь. Күпләр Минин һәм Пожарский исемнәренең халыклар бердәмлеге белән бәйләнеше турында аз гына ишетеп белә иде. Хәзер исә Мәскәүнең поляклардан азат ителү тарихы һәркемгә мәгълүм.
Иң мөһиме- халыклар бердәмлегенең бүгенге көндә никадәр кирәклегенә төшенү.Бердәмлек- ил куәте, икътисади үсеш, илдәге сәяси хәл белән янәшә йөри. Бу төшенчәләр җәмгыятьнең нигезен тәшкил итә. Без авыр вакытта бер- беребезгә ярдәм итәргә, бердәм булырга тиеш. Барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз! Илебезне үстерүдә армый- талмый хезмәт итүегезне телибез.

# Укучыларга киңәшләр!

1. Көндәлек эшләрегезнең планын төзегез.
2. Ни генә эшләсәгез дә, ашыкмый гына эшләргә тырышыгыз.
3. Эшне тиешенчә эшләп бетерә алмасагыз, аның өчен борчылмагыз.
4. Үзегез өчен кыска-кыска яллар оештырыгыз. Әз-мәз генә ял итеп алудан тәм таба белегез.
5. Стрессның беренче билгеләрен танырга (баш, җилкә, бил авырту яки тәннең бер өлеше ою, ашказаны авырту) һәм тән мускулларын йомшарту, киеренкелектән чыгу алымнарын үзлегегездән табарга өйрәнегез.
6. Өметсезлеккә бирелмәгез. Бик кыен хәлгә юлыккан чакларда да берәр уңай нәрсә табарга тырышыгыз. Бер михнәтнең бер рәхәте булмый калмый.
7. Үзегезгә ошаган кешеләр белән генә аралашыгыз.
8. Туклану режимын төгәл үтәргә тырышыгыз. Акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләргә аксымлы ризыклар кирәк. Балык, борчакише ризыкларны ешрак ашагыз.
9. Хәрәкәттә - бәрәкәт икәнен онытмагыз.
10. Бу киңәшләрне үз җаегыз белән генә эшләгез.

**Аглетдинова Гөлләр**

# Юл кагыйдәләрен беләбез, әмма үтәмибез

“Улым, (кызым), юл аша, зинһар, карап чык”, – дигәнне сез еш ишетәсезме? Иманым камил, җәй көне әти-әниләр бу хакта ешрак әйтәләрдер. Җәй, ни әйтсәң дә, хәвефлерәк чор ул. Юлларда машиналар саны кискен арту белән дә бәйле бу, (кыш көне рульгә утырырга кыймаучылар да язга бер-бер артлы килеп чыгалар, аларны әле бик матур исем белән - “чәйнекләр” дип атап йөртәләр), балаларның көн дәвамында урамда, уенда, шартлыча әйтсәк, ирекле булулары белән дә. Балалар бырысы да нигездә юл кагыйдәләрен яхшы беләләр. Әмма, кызганычка каршы... үтәмиләр. Бу җәйге чорга гына хас күренеш түгел, гомумән, шулай.

Иң еш очрый торган кагыйдә бозу исә балаларның урам аша чыкканда җәяүлеләр юлын эзләп тормавы. Малайлар, билгеле, үз көченә ышанучан була, «Әй, мин чыгып өлгермимме соң инде!», дип уйлый. Әмма чит ил машиналарының тизлеге бик югары булуын да, машина йөртүченең аны (бигрәк тә, эңгер -меңгердә), күрмәскә мөмкин булуын да исәпкә алып бетерми. Һәм җәяүлеләр юлын күрү белән атылып чыгарга да ярамый. Башта машинаның туктавын көтегез.

Бер-береңә, тирә-юньдәгеләргә игътибарлы булу ул, кагыйдә буларак, кече яшьтән тәрбияләнә. Әти-әниләр балаларны җәяүле генә түгел, булачак машина йөртүче итеп тә күрсеннәр, һәм һәрвакыт уңай үрнәк күрсәтсеннәр иде. Бүгенгенең йогынтысын без иртәгә һичшиксез сизәчәкбез.

**Закирова Гөлинә**



### Бердәмлектә— көч!



22 ноябрь көнне мәкәбебеәдә Нурлат профсоюз оешмасы председателе Сагирова Фәридә Мөхлис кызы булып ките. Әле беренче елын гына эшләүче мәктәпнең профсоюз җитәкчесе Садртдинова Рузилә Нурислам кызына үзенең киңәшләрен бирде.

### Тату сыйныф секреты



18 нче ноябрь көнне район күләмендә «Тату сыйныф секреты» конкурсы булып узды. Конкурста 17 мәктәп катнашты. Безнең ата-аналар комитеты лаеклы чыгыш ясадылар һәм сертификат белән бүләкләнделәр.

### Бәйрәмгә әзерлек



Озайтылган көн группасына йөрүче балалар Әниләр бәйрәменә бик теләп әзерләнде.Алар булачак бәйрәмдә үз куллары белән ясалган открыткалар бүләк итәләр һәм концерт номерлары әзерлиләр.

# Якыннан танышыйк!





Укучыларның сорауларына башлангыч сыйныф укытучысы Әхмәтова Рузилә Әсхат кызы җавап бирә.

**- Рузилә Әсхатовна, ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз?**

- Кечкенәдән рәсем ясарга бик яраттым. 7 нче сыйныфта укыганда рәсем укытучысы Мазитова Фиалка апа укыта башлады. Рәсем ясауга сәләтем барлыгын күреп, Лениногорск педагогия училищесына рәсем, сызым факультетына укырга барырга киңәш итте .

**- Мәктәптә укыган вакытта Сезнен яраткан фәннәрегез?**

- Әйтеп үткәнемчә, рәсем табигать белеме фәннәрен яратып укый идем.

**- Сезнең яраткан укытучыларыгыз?**

- Математика укытучылары Камил абый һәм Әлфия Галиевна, тарих укытучысы Әнвәр Фәттахович , рус теле һәм әдәбияты укытучысы һәм сыйныф җитәкчебез Нәзимә Вахитовна яраткан укытучыларым һәм остазларым булдылар.

**- Сезнең хоббиегыз нинди?**

- Мин пешерергә яратам, бигрәк тә камыр ризыклары. белән гаиләмне сыйларга җаен да табарга тырышам.

**Хәзерге укучыларга һәм укытучыларга нәрсәләр теләр идегез?**

– Һәр укучының кешегә, ошаган һөнәрен сайлап, тормышыннан тәм һәм ямь табып яшәргә язсын иде. Халыкта: “Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау бәхетне түшендә күрер” дигән мәкаль бар бит. Халык әйтсә, хак әйтә. Коллегаларыма тырыш укучылар, зур дәрәҗә, бәхет, шатлык, сабырлык, тыныч күк йөзе телим.

**Әңгәмәне Хисматова Зәринә алып барды**




# Каникул файдалы узды



Мәктәптә көзге каникул вакытында (30.10.16-05.11.16) **"Спорт—экспресс"** программасы буенча көзге лагерь эшләде. Укучылар үзләренең вакытларын бик күңелле уздырдылар: төрле спорт уеннарында, конкурс, викториналарда катнаштылар, үзләренең белемнәрен арттыру өстендә эш алып бардылар.



## ГРИППТАН САКЛАН!

Грипп – сулыш юлларын ялкынсындыручы инфекцион авыру. Авыру барышында томау, тамак ялкынсыну, ютәлләү, тамак төбе авырту күзәтелә. Куркыныч грипп вирусының организмны агулап, төрле әгъзалар эшчәнлегенә зарар китерүе бик мөмкин. Авыру вакытында югары тән температурасы, баш авырту, тән сызлау, костыру, галлюцинацияләр дә булуы ихтимал.

***Аглиуллин Аяз***

**Тирләтүче чәй эчегез.** Берәр аш кашыгы бал, гөлҗимеш, карлыган, кура җиләген алып 200 мл кайнар суда 15 минут төнәтегез һәм ашар алдыннан көненә өч тапкыр яртышар стакан эчегез. Шуннан соң юрганга төренеп ятыгыз.



# БЕЛЕМЕҢ БУЛСА – “АРТЕК”КА БУШЛАЙ ЮЛЛАМА ДА БУЛА

**Җәеңне күңелле, кызыклы һәм файдалы итеп уздырыйм, дисәң, алмагачтан алма өзелеп төшкәнен генә көтеп ятып булмый. Бераз тырышлык та куярга кирәк әле.**

Рус география җәмгыяте мәктәп укучылары арасында «Артек», «Смена», «Орленок», «Океан» балалар үзәкләренең профиль сменаларына элэгер өчен Бөтенроссия конкурсы игълан итте. Конкурста катнашырга 10-17 яшьлек укучылар – география, экология, этнография, туган якны өйрәнү буенча конкурс-олимпиадалары җиңүчеләре чакырыла.

**Бәйге җиңүчеләре түбәндәге лагерьларның профиль сменаларына юллама алырга мөмкин:**

– «Смена» лагере (сменасы 30 март – 19 апрель аралыгына уза);
– «Орленок» лагере (сменасы 30-31 май – 19-20 июнь аралыгында үтә);
– «Океан» лагере (сменасы 24 июнь – (14 июль аралыганда уза);
– «Артек» лагере (сменасы 30-31 август – 19-20 сентябрь аралыгында үтә).

Бу профиль сменаларда укучылар танылган сәяхәтчеләр, географлар, галимнәр, фотограф, журналистлар белән аралаша алачак. Яшьләр фәнни квестларда катнашып, туризм, туган якны өйрәнү серләренә төшенәчәк.

**Конкурсның сайлап алу турлары интернет-сайтта шушы даталарда үткәрелә:**

– «Смена» лагере (2-25 февраль);
– «Орленок», «Океан» лагере (27 февраль – 9 апрель);
– «Артек» лагере (10 апрель – 2 июль)

## Алар олимпиадаларда мәктәп данын яклаячак

**Октябрь ае буена укучылар төрле фәннәр буенча илкүләм олимпиадаларның мәктәп турында көчләрен сынады. Инде мәктәп данын район турында яклау хокукын алучылар исемлеге билгеле булды.** Болар: инглиз теленнән Гомәрова Лэйсән, Зарипова Зилә,, математикадан Әһлиуллин Аяз, Сөнгатуллина Рәзилә,Гомәрова Лэйсән, биологиядән Гайсин Илшат, Вәгыйзова Лэйсән, Гафурова Алия тарихтан Ахметова Назилә, технологиядән Гомәрова Лэйсән, Зиннуров Разил,Хисматов Рәсим, тормыш иминлеге нигезләреннән Хәйруллин Булат, Гомәрова Лэйсән, Физик тәрбия фәненнән Шагиахмтов Илназ катнаштылар. *Әлеге укучыларга бары тик уңышлар гына телибез.*

## Иң көчлеләр билгеле

**Ниһаять, олимпиадаларның район турында җиңүчеләре дә билгеле булды:** татар теле буенча Гомәрова Лэйсән, Гафурова Алия, Зарипова Зилә, Тагиров Ильмир тормыш иминлеге нигезләре фәненнән Гомәрова Лэйсән,математикадан Гомәрова Лэйсән, Сунгатуллина Рәзилә, химиядән Гайсина Гөлшат, Гафурова Алия, технологиядән Зиннуров Рәзил, Гомәров Ранис, Хисматов Рәсим татар әдәбиятыннан Зарипова Зилә, Гафурова Алия призлы урынга ия булдылар. **Уңышларыгыз белән котлыйбыз!**

# Бүләккә — гөләк!

*Алтын куллар*

*Дускай! Исеңдәме, 23 февраль һәм 8 март бәйрәмнәре якынлашып килә. Син бүләкләр әзерләдеңме әле? Әгәр юк икән, без сиңа иң шәп бүләк ясау серләрен ачабыз. Төп шарт — ул үз кулларың тылсымы ярдәмендә эшләнергә тиеш. Башлыйбыз!*

Бүген төрле төстәге пластилиннан роза чәчкәләре кәрзинен эшләрбез.

1


2


3


4


**1** Коңгырт яки кара төстәге пластилин кисәген ал һәм җайлап кына цилиндр формасына китер. Аңа кәрзин бизәлешендәге кебек сары пластилиннан бауга охшаш берничә деталь ясап беркет. Безнең кәрзин әзер!

**2** Ачык (кызыл, сары, кызгылт, ак) төстәге пластилин кисәген ал, кечкенә шар итеп әвәллә, аны нечкә «коймакчык»ка үзгәрт, аннары «багана» рәвешенә китереп иплә төр. Ул – безнең роза чәчәгенең үзәге. Шул ук төстәге пластилиннан берничә «коймакчык»лар әзерлә, һәрберсен, бер кырыен бераз бөкләп, «багана»бызга беркет. Ахырда роза чәчәге пәйда булачак.

**3** Яшел төстәге пластилин кисәгеннән «комакчык»лар яса. Бер ягын бераз тартыбрак куй, яфракка охшасын. Һәрбер яфрак өчен яшел пластилиннан сабак ясап, икесен бергә беркет, сабак башына чәчкәне дә тоташтырып куярга онытма.

**4** Кәрзинебезнең өстенә һәрбер чәчкәне беркет. Менә безнең роза чәчкәләре кәрзине әзер дә!



**Искиткеч матур, шулаймы?!**



## ИҢ КАДЕРЛЕМ – ӘНИЕМ!

Әни, әнием,әнкәй! Кадерләп назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз,һәрвакыт янybызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез. Халык ана хакын хаклауны Алла хакын хаклауга тиңли. Ана турындагы бер әйтемне искә алыйк: "Ананны. арка кочып, Мәккәгә алып барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың. Анаң өчен уч төбеңдә тәбә куырсаң да, хакын хаклап бетерә алмассың”. Гасырлар аша килеп ирешкән бу гыйбрәтле, канатлы фразаларны җаныбызга, аңыбызга сеңдерү зарур.

Синең өчен кайгыртучы әниең булуы нинди зур бәхет ул. Аны ярату гына җитми, аның кадерләрен белергә, сүзен тыңларга, яхшы укуың, үзеңне үрнәк тотуың, эшкә өйрәнеп үсүең белән ананы шатландырырга кирәк.

*Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез. Халык ана хакын хаклауны Аллаһ хакын хаклауга тиңли. Ана турындагы бер әйтемне искә алыйк: “Анаңны арка кочып Мәккәгә алып барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың. Анаң өчен учыңда тәбә куырсаң да, хакын хисаплап бетерә алмассың”. Гасырлар аша килеп ирешкән бу гыйбрәтле, канатлы сүзләрне җаныбызга, аңыбызга сеңдерү зарур.*






Тырыш булырмын, әни,
Әйбәт булырмын, әни!
Сине мин бик яратам,
Сөендерермен, әни.
Син бит чибәр, акыллы
Тоябыз кайгыртуны.
Син яныбызда булганда
Тоймыйбыз авыртуны.



Ноябрь аенда туучы кадерле

укытучыларыбыз һәм

техник хезмәткәрләребез:

Сөләйманова Раилә Заһит кызы,

Гомәрова Флүсә Фоат кызы,

Садретдинова Гөлназ Ринат кызы,
Хисматова Зәкирә Закирҗан кызы!

Сезгә гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын юллыйбыз. Якты ал таңнар, зәңгәр күкләр сезнең көннәрегезне һәрчак яктыртсын, балкытып торсын. Таң җилләренең назлысы, җан тынычлыгы, чиксез бәхетләр, эшегездә зурдан-зур уңышлар, яхшы, күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә.

Ноябрь аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:

Григорьев Антон, Шәйдуллова Сиринә,
Гайнуллина Алия, Гайнуллин Эдурад,
Садртдинова Рузилә, Таһирова Гайшә,
Фәйзетдинова Алсу!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын көннәрегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!






**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыйм кызы

**Урынбасары:** Аглиуллин Аяз

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Аглетдинова Гөлләр, Закирова Гөлинә, Хайбуллина Әдилә, Хисматова Зәринә.